ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
БАЛТАСИНСКОГО
ГОРОДСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
БАЛТАСИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛТАЧ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
БАЛТАЧ ШӘҺӘР ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
«18» нче апрель 2025 ел

**КАРАР**
№ 74

Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Балтач шәһәр җирлеге территориясендә хуҗасыз хайваннарны кайтару тыела торган урыннарны билгеләү турында һәм хайваннарны элеккеге яшәү урыннарына кайтару турында карарлар кабул итүгә вәкаләтле затлар исемлеген билгеләү турында

2018 елның 27 декабрендәге 498-ФЗ номерлы «Хайваннар белән җаваплы эш итү турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» Федераль законның 18 статьясындагы 6.1 өлеше нигезендә, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законга нигезләнеп, Балтач шәһәр җирлеге Советының 21 нче октябрь 2022 нче елның 63 номерлы карары белән кабул ителгән Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Балтач шәһәр җирлеге Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Балтач шәһәр җирлеге башкарма комитеты карар бирә:

1. Билгеләргә:
1) Балтач шәһәр җирлеге территориясендә хайваннарны хуҗалардан башка кайтару тыела торган урыннар (1 нче кушымта);
2) Балтач шәһәр җирлеге территориясендә хайваннарны хуҗаларыннан башка аларның элеккеге яшәү урыннарына кайтару турында карарлар кабул итүгә вәкаләтле затлар исемлеге (2 нче кушымта).

2. Хуҗаларсыз хайваннарны башка элеккеге яшәү урыннарына кайтару турында карар формасын расларга (3 нче кушымта).

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http:pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының рәсми сайтында халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Балтач шәһәр җирлеге
башкарма комитеты җитәкчесе

И.Д.Габдрахманов

Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Балтач шәһәр җирлеге башкарма комитетының 18 аперель 2025 елгы № 74 карарына 1 нче кушымта

**Хуҗаларсыз хайваннарны Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Балтач шәһәр җирлеге территориясендә кайтару тыела торган урыннар**

1) Парклар, скверлар территорияләре;
2) Балалар өчен уен һәм балалар спорт мәйданчыклары;
3) Актив спорт төрләре белән шөгыльләнү өчен спорт мәйданчыклары, ачык һавада спорт уеннары өчен билгеләнгән мәйданчыклар;
4) Зиратлар һәм мемориаль зоналар;
5) Массакүләм чаралар уздыру өчен мәйданчыклар;
6) Балалар, мәгариф һәм дәвалау учреждениеләре территорияләре;
7) Мәдәният объектларына якын территорияләр;
8) Җәмәгать туклануы оешмаларына якын территорияләр;
9) Сәүдә-күңел ачу үзәкләре территорияләре;
10) Ваклап сату базарлары территорияләре;
11) Йорт хайваннарын йөртү өчен билгеләнгән урыннар;
12) Калдыкларны урнаштыру объектларына якын территорияләр;
13) Калдыкларны туплау урыннары (мәйданчыклары) чикләрендә территорияләр;
14) Җылылык челтәрләре чикләрендә территорияләр.

Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Балтач шәһәр җирлеге башкарма комитетының 18 аперель 2025 елгы № 74 карарына 2 нче кушымта

**Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Балтач шәһәр җирлеге территориясендә хуҗаларсыз хайваннарны элекке яшәү урыннарына кайтару турында карар кабул итүгә вәкаләтле затлар исемлеге**

1) Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Балтач шәһәр җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе - Габдрахманов И.Д.;
2) Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Балтач шәһәр җирлеге башлыгы урынбасары - Закирова Ф.А.;
3) Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Балтач шәһәр җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары - Ибраһимова Р.Р..

Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Балтач шәһәр җирлеге башкарма комитетының 18 аперель 2025 елгы № 74 карарына 3 нче кушымта

ФОРМА

**Хуҗасыз хайваннарны элеккеге яшәү урыннарына кайтару турындагы карар**

от «____» __________ 20__г. № ______

________________________________________________________________________

(Ф.И.О., хуҗасыз хайваннарны элеккеге урыннарына кайтару турында карар кабул итүгә вәкаләтле зат вазыйфасы)

тәкъдим ителгәне нигезендә ____________________________________________

(хайваннарны аулау буенча махсуслаштырылган оешманың тулы исеме)

хуҗасыз хайваннарны аның ветеринария өлкәсендә белгечнең мәҗбүри катнашында комиссия үткәргән агрессивлыгы булу (булмау) предметына тикшерү акты от «___» _______ 20___г. № ____

хуҗасыз хайванга карата:

идентификационный билге ____________________________________________

аулау урыны һәм вакыты ______________________________________________,

Кабул ителгән карар:

________________________________________________________________________

(хуҗасыз хайваннарны элеккеге урыннарына кайтару буенча/кире кайтаруны тыю)

________________________________________________________________________

(кабул ителгән карар куела)

_________________ ______________________________________

(подпись) (Ф.И.О.)